## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлеге составына керүче Восход торак пунктында

13 ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Писмән авыл җирлеге составына керүче Восход җирлегендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Писмән авыл җирлеге составына керүче Восход территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, аларның тол хатыннарыннан тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 500 сум күләмендә билгеләргә:

2. Алынган средстволарны түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- урамнарны яктыртуны оештыру;

-авыл җирлеге юлларын ремонтлау объектларының расланган исемлеге нигезендә җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (юлларны карап тоту һәм ремонтлау эшләре).

Лениногорск муниципаль районы
«Писмән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.В.Насретдинов